ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2020 Олы Кайбыч ав. № 145

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 гыйнварындагы 55 номерлы «2020 елда Кайбыч муниципаль районы территориясендә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» карары нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актны канунчылыкка яраклаштыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 гыйнварындагы 55 номерлы «2020 елда Кайбыч муниципаль районы территориясендә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче кушымтада «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» СДАУ баш табибы» сүзләреннән соң «(килешү буенча)» сүзләрен өстәргә;

4 кушымтаның 6.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Балалар һәм яшьләрнең лагерьларда ялы өчен ата-аналар түләве күләме ял оешмалары тарафыннан билгеләнә. Балалар һәм яшьләрнең ялы өчен ата-аналар түләве Татарстан Республикасы оешмалары тарафыннан билгеләнә, ә башка оешмаларга балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен норматив чыгымнарның 15 проценты күләмендә, әмма ял төрләренә карап юлламаның факттагы бәясенең 50 процентыннан да артыграк булмаган күләмдә билгеләргә тәкъдим ителә»;

4 кушымтаның 10.8. пунктында «2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» Федераль законы белән» сүзләрен «2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының

мәгълүматый-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ruпо веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А.Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров